**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ИВАШКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ул.Центральная, д.1а, с.Ивашкино, 423113

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ИВАШКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Үзек урамы, 1а йорт, Ивашкино авылы, 423113

тел./факс (84396) 3-82-19 email: Iva.Cmn2@tatar.ru

**КАРАР**

**18 сентябрь 2019 ел** **№ 12**

**Референдум үткәрүне кузгату турында**

12.06.2002 ел, № 67 - ФЗ «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» гы Федераль законның 15 статьясы, 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 24.03.2004 ел, № 23-ТРЗ Татарстан Республикасы законы, Ивашкино авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлеге Башкарма комитеты Татарстан Республикасы **КАРАР БИРДЕ:**

Җирле референдум үткәрүне түбәндәге мәсьәлә буенча башлап җибәрергә:

"2020 елда Ивашкино авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүче гражданнардан, 1 төркем инвалидлардан, ялгыз картлардан һәм 90 яшьтән өлкәнрәкләрдән тыш, 400 сум күләмендә үзара салым кертергә килешәсезме?:

-Ивашкино, Әккәрәй авылларында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерүгә, карап тотуга, юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү, юлларны грейдлаштыру, урамнарны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, хезмәтләр өчен түләү) чыгымнар, югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу (хезмәтләр күрсәтү);

- Ивашкино, Әккәрәй торак пунктларында урам утларын монтажлау, урнаштыру, ремонтлау, карап тоту һәм хезмәт күрсәтү, урам утларын кулланган өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу (хезмәтләр күрсәтү);

- Ивашкино, Әккәрәй торак пунктларында җәяүлеләр күперен ремонтлау, югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу (хезмәтләр күрсәтү);

- Ивашкино, Әккәрәй торак пунктларында скважиналарны лицензияләү, экспертиза һәм су анализы өчен түләү;

Әккәрәй урта гомуми белем бирү мәктәбе өчен 50 метр күләмендә койма сатып алу;

- Ивашкино урта гомуми белем бирү мәктәбенең подъезд юлын ремонтлау өчен 30 метрлы түзелеш материаллары сатып алу;

ӘЙЕ ЮК»

2. Әлеге карар мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка игълан ителергә тиеш.

Ивашкино авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе Иванова С. В.